**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«30» октябрь, 2019 ел Иске Дөреш авылы № 17

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Иске Дөреш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 12 ноябренә 10.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авылы Яшьләр, Г.Тукай урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Иске Дөреш авылы , Г.Тукай урамы, 21 йорт янында билгеләргә.
2. 2019 елның 12 ноябренә 13.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авылы Ленин, К.Маркс һәм Мәктәп урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Иске Дөреш авылы, Г.Тукай урамы, 21 йорт янында билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, Иске Дөреш авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Иске Дөреш авыл җирлеге Иске Дөреш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 (алты йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;

2) вак тыш сатып алу һәм юлларга салу.

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
6. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков